# Аллаһның берлегенә һәм Аның камиллек тарафларына

# АКЫЛ ДӘЛИЛЛӘРЕ

**Шәех Гәбдүррахмән ибн Нәсыр әс-Сәгди**

*Гарәп-русчадан тәрҗемә (кайбер кыскарту белән)*

**БисмиЛләһи-р-Рахмәни-р-Рахиим.**

(Рәхмәт иясе һәм Рәхимле булган Аллаһ исеме белән!)

Гыйбадәткә бердәнбер лаеклы булган Аллаһка барча мактаулар һәм ахыргы пәйгамбәр Мөхәммәдкә Аллаһның салаваты һәм сәламе булсын.

Әлеге китапта, ачык һәм аңлаешлы рәвештә, Аллаһның берлегенә һәм Аның камиллек тарафларына акыл дәлилләре китерелә. Һәрберебез белергә тиеш – әлеге мәсьәлә, ягъни Аллаһның берлеге һәм Аның бөтен яктан камиллеге иң бөек, кешеләр өчен иң беренчел, иң файдалы, ачык аңлаешлы мәсьәлә булып тора. Аллаһ Тәгаләнең барлык Изге китаплары һәм пәйгамбәр-рәсүлләре шуның белән җибәрелде.

Пәйгамбәр-рәсүлләрнең иң мөһим һәм иң беренчел чакыруы да – әлеге мәсьәләне кешеләргә җиткерү иде, һәрбер рәсүл үзенең кавеменә болай дип әйтә торган булган: **“Ий каумем! Фәкать Аллаһка гына гыйбадәт кылыгыз, Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы иләһегез юк”.** (“Әль-Әграф” сүрәсе, 59-нчы аять). Һәм үзләренең өммәтләрен Аллаһ Тәгаләнең күркәм исем-сыйфатларын, Аның иксез-чиксез нигъмәтләрен исләренә төшереп, Аллаһка карата түбәнчел булып гыйбадәт кылуга өндәгәннәр.

Бөек Коръән дә, пәйгамбәребез Мөхәммәднең ﷺ Сөннәте дә, башыннан алып ахырына хәтле, әлеге мәсьәләне күп төрле дәлилләр китереп аңлаталар, аять-хәдисләр аша бөтен яктан җиткерәләр.

Әмма безнең бу китаптагы максатыбыз Коръән аятьләрен һәм пәйгамбәребез Мөхәммәднең ﷺ хәдисләрен генә китерү түгел, чөнки, әйтеп узганча, Аллаһның берлеге һәм Аның бөтен яктан камиллегенә кагылышлы аять-хәдисләр иксез-чиксез күп, бу гыйлем ияләренә дә, гади кешеләргә дә ачык мәсьәлә, күп кешеләргә әлеге мәсьәләне аңлау өчен бу дәлилләрнең бик аз өлеше генә дә җитә. Әмма без бу китапта Аллаһның берлеге һәм Аның бөтен яктан камиллегенә ишарә булып торучы кайбер <u>акыл дәлилләрен</u> китерергә телибез, чөнки әлеге дәлилләр белән акылы булган һәрбер кеше килешә, һәм аларны, бары тик, дингә һәм сәламәт акылга каршы торучы горур һәм тәкәббер кеше генә кире кага. Әлеге мәсьәлә бик гади һәм ачык, хәтта аны аңлату өчен дәлилләр китерү дә артык булыр кебек, әмма мөэмин-мөселман өчен әлеге дәлилләр аның иманы һәм инануы артуга сәбәп булыр, бу бөек нигъмәтне аңлауга китергән Раббысына шөкер итүен тагын да арттырыр. Пәйгамбәрләр дә үзләренең кавемнәренә әйтә торган булганнар: **“Әллә җирне вә күкләрне бар кылучы Аллаһка шик тотасызмы?”** (“Ибраһим” сүрәсе, 10-нчы аять). Чынлыкта бу сорау шелтә белдерү өчен китерелгән, чөнки акылы дөрес булган кеше Аллаһның барлыгын, Аның бердәнбер галәмнәр Раббысы, бердәнбер гыйбадәткә лаеклы зат булуын яхшы аңлый.

Һәм инде, Аллаһның ярдәменә таянып башлыйбыз:

## <u>БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК.</u>

### <u>Беренче дәлил: барча мәхлукатның[1] барлыкка килүенә, акыл-фикер ягыннан, өч төрле вариант китерергә була.</u>

Бел, Аллаһ сиңа рәхимле булсын, әгәр дә син күкләрдәге, җирдәге зур һәм вак булган барча нәрсәләрнең барлыкка килүе, заманның төрле вакытында баручы вакыйгалар, процесслар турында уйлансаң һәм дөрес фикер йөртсәң – бу әйберләрнең барлыкка килүенә акыл ягыннан өч төрле вариант булуы мөмкинлеген аңлыйсың:

<u>беренчесе</u>, бу нәрсәләр һәм процесслар бар итүчесез, ягъни үзлегеннән барлыкка киләләр. Ләкин акылы булган кеше мондый вариант мөмкин түгел икәнен белә һәм моның белән килешкән кешене акылсызлыкта гаеплиячәк. Чөнки һәрбер кеше яхшы аңлый – нәрсәдер булсын өчен, аны бар итүче булырга тиеш;

<u>икенчесе</u>, әлеге бар ителгән әйберләр үз-үзләрен бар иткәннәр. Бу вариант та мөмкин түгел, чөнки һәрбер кеше бер әйбер дә үз-үзен барлыкка китерә алмаганын яхшы аңлый. Шуңа күрә, акылы булган кеше, бер әйбер дә бар итүчесез, үзлегеннән барлыкка килә алмаган кебек, үз-үзен дә барлыкка китерә алмаганын таный. Димәк, бары тик бер генә вариант кала:

<u>өченчесе</u>, барча нәрсәнең һәм процессларның бар итүчесе бар, һәм Ул әлбәттә – һәрбер әйберне юктан бар кылучы, бөтен мәхлукат белән идарә итүче Галәмнәр Раббысы – Бөек Аллаһ. [Яхшырак аңлау өчен бу вариантларга гади мисал китерергә була: мәсәлән, берәр кем әйтә ди “*хәзер менә бу өстәлдә кинәт кенә үзлегеннән каләм барлыкка киләчәк*”, әлбәттә бу мөмкин түгел, һәрбер кеше мондый сүзгә “*җүләрләндеңме әллә?*” дип әйтәчәк; шуннан соң ул “*юк, ул үзлегеннән түгел, ә үз-үзен барлыкка китерәчәк*” дип әйтсә, шулай ук, бу кешене җүләрлектә гаеплиячәкләр. Димәк, өченче вариант кына кала – каләм өстәлдә барлыкка килсен өчен, аны <u>кемдер</u> бу өстәлгә алып килеп куярга тиеш. Ягъни гади бер каләм үзлегеннән барлыкка килә алмаган кебек, әлеге каләмне уйлап тапкан кеше дә үзлегеннән бар килә алмас! [Тәрҗемәчедән].

Әгәр дә без Коръәнне ачып карасак, Аллаһ Тәгаләнең шушы акыл вариантларын китергәнен күрәбез: **“Әллә алар үзлегеннән бар булдылармы, әллә үз-үзләрен бар кылдылармы? Әллә җирне вә күкләрне алар бар иттеме? Бәлки аларның моңа инануы аздыр”.** (“Әт-Тур” сүрәсе, 35-36 нчы аятьләр).

Ягъни, бар-булганны – бар итүче, эзне – эз калдыручы, ясалган әйберне – ясаучы, гамәлне – гамәл кылучы булырга тиеш. Бу хакыйкатьне барча кеше аңлый һәм аның

---

[1] Аллаһ бар кылган тере яки җансыз булган барча нәрсәләр бер сүз белән “мәхлукат” дип әйтелә.

белән килешә, ә инде берәр кем монда шикләнсә, бу әлеге кешенең акылында гаеп булуына күрсәткеч булып тора.

**<u>Икенче дәлил: кешенең һәм барча галәмнең яратылуы турында фикерләү.</u>**

Уйла, Аллаһ сиңа рәхимле булсын, үзеңнең яратылуың, ягъни юктан бар булуың турында – ничек итеп син бер этаптан икенче этапка күчеп бер тамчы судан, соңрак ул судан оешкан кан булып, соңрак ул каннан ит кисәге булдың, һәм аннан соң, тышкы һәм эчке органнары үз урынында урнашкан камил кыяфәтле кешегә әйләндең. Бу бит сине һәрнәрсәгә көче житүче, барча әйберне белүче һәм хикмәт белән эш итүче Раббыңны тануга китерергә тиеш. Җир йөзендә яшәүче барча кешелек җыелып, синең яратылуың башланган бер тамчы суны алып, әлеге катлаулы һәм тәртипкә салынган төрле этаплар аша уздыра алырлар идеме?! Аны, яралгы өчен һәръяктан саклаучы һәм имин урын булып торучы ана карынына куеп, кешедә булган тышкы һәм эчке органнар, куәт һәм төрле сәләтләр бар итерләр идеме?! Ишетүче колаклар, күрүче күзләр, акыл урнаштыра алырлар идеме?! Шушы гаҗәеп булган, искиткеч тәртипкә салынган, һәрбер әгъзасы үз урынында урнаштырылып үзенең тиешле функциясен башкарган камил җан иясен бар итүгә гыйлемнәре һәм кодрәтләре җитәр идеме икән?! Болар турында фикерләү кешене, әлбәттә, Аллаһ Тәгаләнең берлеген, кодрәтен һәм бөеклеген тануга, Аңа түбәнчелек белән буйсынуга, Изге китапларына, пәйгамбәр-рәсүлләренә, Кыямәт көненә инануга китерергә тиеш.

Шулай ук, сине чолгап алган барча галәм турында фикерлә – ничек итеп Аллаһ Тәгалә аны саклый һәм кайгырта. Анда бит төрледән-төрле, без күргән һәм Аллаһның Үзеннән кала беркем дә белмәгән гаҗәеп нәрсәләр бар. Шул галәмне камил тәртиптә тоту өчен анда нинди генә процесслар бармый, нинди генә табигый законнар һәм системалар урнаштырылмаган. Болар бит барысы да әлеге галәмнең Раббысы булуы, Аның берлеге, киң гыйлеме һәм бөтен нәрсәне чолгап алган хикмәте турында сөйли. Аллаһ Тәгалә Коръәндә моңа карата да акыл дәлилен китерә: **“Аллаһның могҗизасыдыр – җир вә күкнең терәүсез Аллаһның әмере белән торулары”.** (“Әр-Рум” сүрәсе, 25-нче аять). Шулай ук: **“Аллаһ җирне вә күкләрне төшеп китүләреннән үзенең кодрәте белән тотадыр, әгәр җир вә күкләр урыннарыннан китсәләр, аларны Аллаһтан башка тотып калучы һич булмас. Аллаһ йомшаклык кылучы вә ярлыкаучы”.** (“Фәтыр” сүрәсе, 41-нче аять).

Уйла, кардәшем, үз орбитасы буенча йөрүче күк җисемнәре турында – шул сәбәпле төн белән көн, вакыт һәм ел фасыллары алмашына. Болар барысы да кешеләр һәм башка җан ияләренең мәнфәгатьләрен кайгырту, аларга исәпсез-хисапсыз файдалар китерү өчен куелган.

Бу санап үтелгән гаҗәеп әйберләр, төгәл законнарга буйсынган камил процесслар үзеннән-үзе, очраклы рәвештә, беркемнең дә катнашы булмыйча бар ителеп, бернинди

дә идарәчесез булуы мөмкинме икән?! Әлбәттә, бу искиткеч төзелгән галәм – Аллаһ Тәгаләнең иҗаты: **“Бар нәрсәне камил кылган Аллаһның иҗаты шундыйдыр”.** (“Ән-Нәмел” сүрәсе, 88-нче аять).

Аннан соң, Аллаһ сиңа һидәят бирсен, кара – Аллаһ Тәгалә һәрбер әйбергә тиешле төзелешен биргән һәм шул әйбер яшәсен яки юкка чыкмасын өчен, аны – аның өчен кирәкле булган яшәү чыганакларына юнәлткән, төрле файдалы әйберләр биргән яки табырга өйрәткән. Хәттә телсез булган төрледән-төрле олы һәм вак җан ияләре, җәнлекләр дә – һәрберсе моңа өйрәтелгән. Әгәр дә кеше әлеге җан ияләренең мәнфәгатьләре гаҗәеп рәвештә кайгыртылган, алар файдалы, яшәү өчен кирәк булган барча әйберләрне табарга, зыян китерә торган нәрсәләрдән ерак булырга тулысынча өйрәтелгән һәм акылларына салынганлыгы турында фикерләсә – ул, әлбәттә, әлеге галәмнең, җан ияләренең Бар итүчесе, Тәрбиячесе һәм Кайгыртучысы барлыгына инанырга тиеш. Бу Аллаһ Тәгаләнең берлегенә һәм камиллегенә ачык дәлилдер.

Коръәндә Аллаһ Тәгалә моңа игътибарны юнәлтә, Муса пәйгамбәр ﷺ белән Мисыр патшасы фиргавен арасында булган әңгәмәдә, фиргавен Муса пәйгамбәрдән аның Раббысы турында сорый һәм Муса пәйгамбәр “Таһә” сүрәсе, 50-нче аятьтә: **“Безнең Раббыбыз Үзе бар кылган әйберләренә тиешле табигать бирде һәм, аннан соң, Үзе биргән нәрсәләрдән файдаланырга юл күрсәтте.”** – дип җавап бирде.

Безне чолгап алган төрле җан ияләренең, җәнлекләрнең, тормышлары өчен кирәк булган барча нәрсәгә өйрәтелгәнлеге, үзләренең балаларына карата рәхмәт һәм мәрхәмәт салынганлыгы, балалары үсеп җитеп, әти-әнисеннән башка яши алганчыга хәтле тәрбияләүләре турында фикерләсәк – Аллаһ Тәгаләнең киң рәхмәтен, барча әйберне чолгап алган гыйлемен һәм хикмәтен күрербез.

## <u>Өченче дәлил: Аллаһның киң рәхмәте турында фикерләү.</u>

Аннан соң, Аллаһ сиңа рәхимле булсын, Аллаһ Тәгаләнең бөтен галәмнәрне, барча җан ияләрен һәрбер халәтләрендә чолгап алган киң рәхмәте турында фикерлә. Аллаһның рәхмәте сәбәпле җансыз әйберләр һәм җаны булган барча тереклек бар булды, Аның рәхмәте белән болар барысы да юкка чыгудан кайгыртылып һәм сакланып, һәм, шулай ук, Аллаһның рәхмәте белән, аларның һәрберсе яшәеш өчен кирәкле булган ачыктан-ачык һәм яшерен нигъмәтләр белән тәэмин ителеп торалар. Шуннан башка бернинди тереклек һәм яшәеш бер мизгел дә тора алмас иде! Аллаһ Тәгалә Үзенең җан ияләрен диннәренә һәм тормышларына кирәк булган барча нәрсәгә өйрәткән, аларның тәннәренә һәм аерым органнарына иминлек биргән, нәсел һәм балалар белән ныгыткан, киң ризык, иген-уңыш, җиләк-җимешләр, мал-терлек, куллану өчен төрледән-төрле предметлар, яхшы йортлар, рәхәтлек һәм иркенлек биргән. Бу нигъмәтләр аша барча тереклек үзенә файдалы булган нәрсәләргә ирешә яки, киресенчә, зыянлы булган әйберләрдән имин булып тора. Һәм, әлбәттә, әлеге

фикерләү аркылы без Аллаһ Тәгаләнең берлегенә, Аның киң рәхмәтенә, иксез-чиксез юмартлыгына төшенеп, Аңа карата түбәнчел булырга, нигъмәтләренә шөкер итергә, гамәл-гыйбадәтләребездә ихласлы булырга тиешбез. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Барча әйберне бар кылучы Аллаһ Тагалә һичнәрсәне бар итергә хәленнән килмәгән затлар белән бертигез булырмы?”.** (“Ән-Нәхел” сүрәсе, 17-нче аять). Шулай ук: **“Сездә булган барча нигъмәт – һәммәсе Аллаһтандыр, әгәр сезгә бер зарар ирешсә, тавыш белән Аллаһка ялварасыз.”** (“Ән-Нәхел” сүрәсе, 53-нче аять).

**<u>Дүртенче дәлил: бәлага юлыккан кешеләрнең хәлләре турында фикерләү.</u>**

Шуннан соң, төрле авыр хәлгә төшеп бәлага юлыккан кешеләрнең хәлләренә карыйк: мескенлеккә калган фәкыйрьләр, интектергеч көчле чир белән авыртучылар – һәммәсе дә әлеге кыен хәлләреннән үзләренең көчсезлекләрен күрсәтеп Раббыларыннан ярдәм сорыйлар, көтәләр. Һәм менә, кинәттән, күптән көтелгән җавап килә – кайгы-борчулар юкка чыгып җиңеллек белән алышына.

Әллә бу Аллаһның берлегенә, Аның белеменә һәм киң рәхмәтенә, мәрхәмәтлегенә, һәрбер җан иясенең Аңарга мохтаҗлыгына бөек дәлилләрнең берсе түгелме?! Әлеге акыл дәлиленә Аллаһ Тәгалә Коръәндә игътибарны юнәлтә: **“Бәлага төшкән кеше дога кылса, аның догасын кабул итеп зарарны җибәрүче һәм сезне җиргә хуҗа кылучы Кем булыр? Аллаһтан башка берәр илаһ моны эшләрме? Бик аз вәгазьләнәсез. Төн караңгылыгында сезне корыда һәм диңгездә йолдызләр белән адаштырмыйча йөртүче, вә яңгыр алдыннан рәхмәт җилен җибәрүче Кем булыр? Аллаһтан башка хак илаһ бармы? Аларның Аллаһка тиң итеп гыйбадәт кыла торган затларыннан Аллаһ пакъ һәм бөектер”.** (“Ән-Нәмел” сүрәсе, 62-63 нче аятьләр). Шулай ук: **“Әгәр алар көймәгә утырсалар диннәрендә ихласлык күрсәтеп Аллаһка ялваралар, Аллаһ аларны диңгездән коткарып корыга чыгарса, яңадан ширеккә әйләнеп кайталар.”** (“Әл-Гәнкәбүт” сүрәсе, 65-нче аять). Шулай ук: **“Сезне төрле сәбәпләр белән җирдә вә суда йөртүче зат – Аллаһ, хәтта сез зур корабларда булсагыз, ул корабларны яхшы җил йомшак кына алып китсә, шул хәлдә шатланып кына барганда көчле җил чыгып, төрле яктан дулкын килсә һәм чорнап алган дулкын һәлакәтлеге килде дип белсәләр, шул вакыт алар Аллаһ диненә кайтып, ихлас рәвештә Аллаһка дога кылырга тотыналар: “Йә Рабби, әгәр безне бу һәлакәттән коткарсаң, әлбәттә, нигъмәтләреңне танып шөкер кылучылардан булырбыз”. Әгәр Аллаһ аларны коткарса, шуннан соң алар җир өстендә бозыклык кыла башлыйлар. Йә кешеләр! Бозыклыгыгыз үз зарарыгызга, дөньяда файдалануыгыз бик аздыр, соңрак Безнең каршыбызга кайтарылачаксыз, шул вакытта кылган эшләрегез белән сезгә хәбәр бирербез.”** (“Йуныс” сүрәсе, 22-23 нче аятьләр).

Әлеге акыл дәлилен бәлки кешеләрнең һәрберсе үзендә сизгәндер, үз күзләре белән төрле исәпсез-хисапсыз тормыш вакыйгаларында күргәндер. Кыен хәлдә калу кешене

Аллаһның барлыгын һәм берлеген тануга китергә – чынлап та, уйлап кара, бәлага юлыккан кеше ничек итеп үзенең калебе белән Раббысына юнәлә, бәлки теле белән Аннан кат-кат ялварып сорыйдыр һәм күңеле белән коткаруны, ярдәмен көтәдер. Бу вакытта ул Аллаһтан унга да һәм сулга да тайпылмый, чөнки ул яхшы аңлый – Аңардан кала беркемгә дә кайту һәм сыену урыны юк, аны бу халәттән Аллаһтан башка беркем дә коткара алмый. Ни өчен шулай соң? Чөнки Раббысының барлыгы һәм берлеге, Аңарга мохтаҗ булуы, Аллаһның гына ниндидер файда китерүе яки зарар җибәрүе, барча милек Аның кулында булуы – болар барысы да һәрбер кешенең һәм һәрбер җан иясенең күңеленә салынган. Ләкин моны үзенең табигый халәтен төрле ялгыш фикерләр белән тутырган кеше генә кире кага.

Шулай итеп, кара – һәрбер җан иясе үзенең һәр халәтендә һәм вакытында Раббысына мохтаҗ. Башта аларны юктан бар кылучы, бар булгач, тормыш өчен кирәк булган әйберләр белән тәэмин итеп торучы, һәм аларга файдалы булган барча әйберләрне булдыручы, зыян булган нәрсәләрдән имин кылучы Раббылары кирәк. Алар үзләренең телләре яки күңел халәтләре белән Раббыларына мөрәҗәгать итәләр, һәм Ул аларга һәрбер кирәк нәрсәләрне биреп тора, бәлалардан коткара, шуңа күрә аларның омтылыш-теләкләре Раббыларына гына юнәлгән, авырлыклар килсә, Аннан гына сыену урыны эзлиләр. Күпме кешеләрне Ул кыенлыклардан коткарды, күпмеләрнең кайгыларын таратты, күпмеләрне фәкыйрьлектән чыгарды, күпмеләрне һәлакәттән һәм бәладән имин кылды! Җан ияләренең Раббыларына мохтаҗ булуы – һәрбер кеше өчен билгеле күренеш, моны бары тик тәкәббер кеше генә кире кага.

**<u>Бишенче дәлил: Аллаһның догаларга җавап бирүе.</u>**

Шулай ук, Аллаһ Тәгаләнең галәмнәр Раббысы булуына һәм Аның берлегенә күрсәткеч буларак, дога кылучыларның догаларына җавап килү тора. Нинди генә кеше булмасын – тәквамы яки бозыкмы, мөселманмы яки мөселман булмаганмы – тормышларының төрле вакытларында Аллаһ Тәгалә барысына да җавап бирә. Бик күп очракларда әгәр дә кешедән “синең бу нигъмәткә ирешүеңә яки бу бәладән котылуыңа нәрсә сәбәп булды?” – дип сорасаң, ул – Аллаһка, Аның рәхмәтенә өмет иткән хәлдә чын күңеленнән дога кылудан кала башка нәрсәне әйтә дә алмаячак!

Әлбәттә, бу һәрвакытта ачык күзәтелә торган дәлилдер һәм моны, бары тик, хаклыкка каршы килүче кеше генә инкяр итә.

Кешеләр үзләренең диннәренә һәм дөньяларына кирәк булган барча нәрсәне Раббыларыннан сорыйлар, һәм Раббылары аларга җавап бирә: **“Кешеләрдән шундый бардыр, ул әйтәдер: “Раббыбыз! Безгә дөньяда теләгәнебезне бир”, – дип. Әмма ахирәттә аңа бернинди дә өлеш калмас. Ләкин кешеләрдән шундый бардыр, ул әйтәдер: “Раббыбыз! Безгә дөньяда да һәм ахирәттә дә яхшылыкны бир һәм**

**безне җәһәннәм утыннан сакла", – дип. Аларга кәсеб иткән гамәлләре өчен Аллаһтан өлеш булыр".** ("Әл-Бәкъара" сүрәсе, 200-202 нче аятьләр).

**<u>Алтынчы дәлил: пәйгамбәрләрнең могҗизалары.</u>**

Аллаһ Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә тагын бер дәлил булып, Аллаһның пәйгамбәрләр аша гадәти булмаган вакыйгалар һәм төрле могҗизалар күрсәтүе тора. Аллаһ әлеге могҗизаларны Үзенең пәйгамбәрләренә биреп, аларга дөньялыкта ярдәм күрсәтте. Әгәр дә тарихка күз салсак, пәйгамбәрләрнең чакыруы мактаулы һәм җиңүле булды, ә аларның дошманнары, киресенчә, ахыр чиктә ярдәмсез калып, Аллаһ Тәгалә тарафыннан төрле газабка дучар булдылар.

Әлеге тарихи вакыйгалар барча кешеләргә дә билгеле. Пәйгамбәрләрнең могҗизалары, аларның җиңүле чакыруы буыннан-буынга сөйләнеп, кешеләр арасында таралып килә. Әлеге факт, күктә кояш белән ай ачык күренгән кебек, яхшы билгеле. Бу әлбәттә, пәйгамбәрләрне җибәргән Аллаһның галәмнәр Раббысы булуына, Аның берлегенә, бөек хакимлегенә, камил кодрәтенә, киң гыйлеменә һәм хикмәтенә бер күрсәткеч булып тора.

**<u>Җиденче дәлил: Аллаһның Изге Китаплары һәм шәригате.</u>**

Аллаһ Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә иң бөек күрсәткеч булып, Аллаһ Тәгаләдән барча пәйгамбәрләргә иңгән Изге Китаплар һәм шәригать, шулай ук, ахыргы пәйгамбәре Мөхәммәдкә ﷺ иңгән Коръән һәм Сөннәт тора. Шуның аша Аллаһ кешелеккә аларның диннәрен, дөньяларын, барча тормышларын дөресли һәм яхшырта торган камил булган хөкемнәр җибәрде.

Коръән белән Сөннәттә һәрбер кеше, нинди халыктан һәм милләттән булуына карамастан, үзенең тормышындагы төрле халәте һәм вакыты өчен нәсыйхәт-сабак алырлык, сыйфатлап һәм санап бетерә алмаслык иксез-чиксез билгеләр, хөкемнәр һәм вакыйгалар табыр: **"Бу – хаклык икәне ачыкланганга хәтле, аларга бөтен галәм төзелешеннән һәм кешеләрнең яратылышыннан Безнең кодрәтебезгә һәм берлегебезгә күрсәткеч булган ачык билгеләрне күрсәтербез".** ("Фуссыләт" сүрәсе, 53-нче аять). Шулай ук: **"Сиңа һәрнәрсәне ачык аңлатучы һәм мөселманнарга һидәят, рәхмәт һәм сөенеч булучы Китапны иңдердек."** ("Ән-Нәхел" сүрәсе, 89-нчы аять).

Әгәр дә без, Коръәндә булучы төрле хак хәбәрләр, гадел һәм төгәл шәригать, кешеләрнең тормышларын һәръяктан төзәтүче, барча мәнфәгатьләрен кайгыртучы, яхшыны рөхсәт итүче, начарны тыючы камил хөкемнәр һәм һидәят турында фикерләсәк, әлеге Коръән – мактаулы, юмарт һәм хикмәт иясе булган галәмнәр Раббысыннан иңгәнлеген танырга мәҗбүр булырбыз.

Нәкъ шулай ук, Мөхәммәд пәйгамбәргә ﷺ Коръән белән бергә бирелгән Сөннәттә булучы камил шәригать, гади һәм ачык дин, туры юл турында фикерләсәк – болар барысы да кеше уйлап чыгара алырлык әйбер түгел икәнен аңларбыз. Хәттә, Коръән белән Сөннәттән берничә хөкемне карау гына да җитәр иде, инде барча хөкемнәр турында фикерләсәк ни диярбез?! Ягъни, мондый камил булган һәм төгәл хөкемнәр – Үзенең барча галәм белән идарә итеп тәкъдир кылуында һәм шәригать хөкемнәрендә хикмәт иясе Аллаһ Тәгаләдән булуын танырга тиешбез.

## Сигезенче дәлил: кешенең табигый халәте.

Аллаһ Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә тагын бер дәлил: кеше шулай бар ителгән – ул күңеле белән үзен бар кылучы Раббысын, Аның һәрнәрсәгә җитүче кодрәтен һәм ихтыярын таный, ягъни безне чорнап алган галәмдә һичнәрсә дә Аллаһның кодрәтеннән һәм ихтыярыннан чыга алмый. Ә бит кеше һәм башка җан ияләре – барысы да тормышлары өчен кирәк һәм файдалы булган нәрсәләргә ия булуга һәм, киресенчә, зыянлы һәм начар әйберләрдән саклануга мохтаҗ.

Җан ияләренең Раббыларына мохтаҗлыгы – иң беренчел булып тора. Шуңа күрә, кеше табигый халәте белән шуны белә: аны бар кылучы, аның хуҗасы, тормыш итү өчен файдалы һәм кирәк нәрсәләрне биреп торучы – бердәнбер Аллаһ. Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Аллаһ кешеләрне әлеге табигый халәттә бар кылды! Аллаһ тарафыннан куелган төзелеш-халәтне үзгәртмәгез! Әйе, бу туры һәм хак диндер.”** (“Әр-Рум” сүрәсе, 30-нчы аять). [Әйтеп узарга кирәк, әлеге табигый халәт (ягъни Аллаһ Тәгалә – галәмнәр Раббысы булуны тану) кешенең тормышында ниндидер проблема-мәшәкатьләр чыкканда яки берәр бәла-каза килгәндә аеруча ачык беленә. Чөнки кеше иминлек-тазалыкта, байлыкта булганда Раббысын онытып җибәрә, ә инде Аллаһ Тәгалә кешедән Үзенең берәр нинди нигъмәтен ала икән, шул вакытта кеше үзенең көчсезлеген һәм Раббысына мохтаҗлыгын аңлый башлый, күңеле һәм теле белән Аңарга ялвара. [Тәрҗемәчедән].

Әлбәттә, кеше Аллаһ Тәгалә тарафыннан куелган чиста табигый халәттә калыр иде, әмма шайтан үзенең эшен эшли – кешеләрнең күңелләренә ялган ышанулар, уйдырма фикерләр, хаталы карашлар сала. Әгәр дә кеше әлеге батыл карашлар тәэсиреннән тумыштан имин булса, Раббысын танып, уңга-сулга авышмыйча бер Аңарга гына юнәлеп, Аннан гына тормышы өчен кирәкле булган әйберләр сорап, Аңа гына барча гыйбадәтләрен юнәлтеп, Аның каршында түбәнчел булып яшәр иде.

## Тугызынчы дәлил: игелек кылучылар бу дөньяда ук үзләренең игелекле гамәлләренең яхшы нәтиҗәләрен күрәләр һәм, киресенчә, залимнәр үзләренең начар гамәлләренең ачысын бу дөньяда ук татыйлар.

Аллаһ Тәгаләнең барлыгына, берлегенә һәм киң рәхмәтенә тагын бер дәлил: яхшылык кылып яшәүче кешегә Аллаһ Тәгалә инде бу дөньяда ук бәхетле тормыш биреп, аңа

Үзенең нигъмәтләрен арттыра. Бу кеше туганлык җепләрен саклый һәм ныгыта, авыр хәлдә калганнарга һәм мохтаҗларга игелек күрсәтә, сәдакалар бирә һәм гомерен башка төрле изгелекләрдә үткәрә. Аның изгелегенә карата Аллаһ та аңарга изгелек күрсәтә – малын арттыра һәм бәрәкәт бирә, ризык табу юлларын җиңеләйтә һ.б.

Уйлап-фикерләп караган кеше, моның сәбәбе – әлеге кешенең изге гамәлләре, аның туганлык җепләрен ныгытуы, Аллаһның колларына карата мәрхәмәтлелеге икәнен яхшы аңлый. Әлбәттә, болар барысы да – җан ияләрен һәм аларның гамәлләрен күзәтеп торучы Аллаһка бер дәлил булып тора. Ягъни, Аллаһ Тәгалә бу кешегә, Кыямәт көнендәге бөек әҗереннән алдан ук, инде бу дөнъяда аңа Үзенең рәхмәтен бирергә ашыга.

Аллаһ Тәгаләнең изгелек кылучыга карата изгелек кылуына төрле мисаллар күп булыр иде, хәтта кешеләр үзләренең тормышларында моның белән бәйле гаҗәеп хәлләр күрәләр. Аллаһ бит әйтте: **“Тиешле урыннарга Аллаһ ризасы өчен нәрсә генә сарыф итсәгез дә – Аллаһ сезгә арттырып кайтарыр.”** (“Сәбә” сүрәсе, 39-нчы аять). Шулай ук: **“Әгәр нигъмәтләремә шөкер итсәгез, сезгә тагын да арттырырмын.”** (“Ибраһим” сүрәсе, 7-нче аять). Пәйгамбәребез ﷺ әйткән: **“*Кем үзенең ризыгы киң һәм гомере озын булуын тели – шул туганлык җепләрен ныгытсын.*”** (Имам Бохари һәм имам Мөслим китерәләр).

Күпме игелек кылучыга Аллаһ Үзе игелек кылды! Күпме сәдака бирүчеләрнең малларын тагын да арттырды! Күпме туганлык җепләрен ныгытучыларның һәм җан ияләренә карата мәрхәмәтле булучыларның калебләрен һәм тормышларын дөресләде, аларны төрле бәлалардан саклады!

Һәм, киресенчә, күпме залимнәр, җан ияләрен кыерсытучылар, туганлык җепләрен өзүчеләр, җинаятьчеләр үзләренең начар гамәлләре бәрабәренә карата, инде бу дөнъяда ук Аллаһ Тәгалә тарафыннан төрле җәзага һәм газабка дучар булдылар! Кешеләр бу залимнәрнең ахыр чиктә һәлакәткә юлыгуларын үз күзләре белән күрделәр һәм моның сәбәбе – аларның начар гамәлләре икәнен яхшы аңладылар.

Кем тирә-юньдәге төрле вакыйгалар һәм Аллаһның көн-дәверләрне алмаштырып торуы турында фикерләп караса, әлеге хәлләрнең кешеләрнең яхшы яки начар гамәлләре белән бәйлелеген күрер. Һәм бу, әлбәттә, Аллаһ Тәгаләнең берлегенә, Аның барча дөньялыкны күзәтеп торуына, Аның гадел булуына һәм киң рәхмәтенә ачык дәлилдер. Шундый кагыйдә бардыр: әгәр дә берәр нәрсә ниндидер сыйфатларга яки фигыльләргә күрсәтә икән, димәк ул – бу сыйфатларга ия булучыга һәм фигыльне кылучыга да күрсәтә. Шуннан инде аңлашыла – югарыдагы һәм түбәндәге барча галәм, үзенең барлыкка килүендә, юкка чыкмыйча торуында һәм барча ихтыяҗларында үзенең Раббысы Аллаһка таяна.

## **ИКЕНЧЕ БҮЛЕК.**

### **Аллаһны тану юллары.**

Шуны аңларга кирәк – Аллаһны тану юллары иксез-чиксез күп, чөнки барча тереклек Раббысыннан нәрсәгәдер мохтаҗ һәм үзенең мохтаҗлыгын һәрберсе үзенчә чагылдыра. Әлеге юллар бер кешедән икенче кешегә карата бертөрле яки аермалы булырга мөмкин, чөнки болар кешенең тормышындагы хәлләренә һәм халәтенә бәйләнгән.

Гомумән алганда, кешенең калебенә керүче уй-фикерләр, күзләре белән күрүче төрле вакыйгалар, сизү органнары белән тоемлап була торган барча нәрсә – хәрәкәтләнүче яки бер урында тик торучы булсынмы, тере яки җансыз булсынмы – барчасы да Аллаһ Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә күрсәткеч булып тора. Шагыйрь әйткәнчә:

Һәрнәрсәдә Аллаһка билге бардыр,

Аның берлеген күрсәтеп торадыр.

Ләкин, Аллаһка күрсәткеч булып торучы тормыштагы аерым мисаллар һәм очраклар кешеләрнең күңелләренә тизрәк үтеп керә һәм акылларына да яхшырак ирешә. Шуңа күрә, әлеге бүлектә без җир йөзендә яшәп киткән һәм хәзер яши торган кешеләрнең тормышларыннан мисаллар китерербез.

### **Аллаһка күрсәткеч булып торучы кайбер мисаллар һәм очраклар.**

Бер кешедән сораганнар: *“Син ничек Раббыңны таныдың?”*. Ул болай дип җавап биргән: *“Дөянең тизәге – бу җирдән дөя узганын, ә юлдагы эзләр – бу юлдан кемдер үткәнен күрсәтә. Шулай булгач, йолдызлыклар белән тулган күк, төрле юллар һәм үзәнлекләр белән тулган җир, дулкыннар белән тулган диңгез – мәрхәмәтле һәм һәрнәрсәне белеп торучы Аллаһ Тәгаләгә күрсәткеч түгелме?!”*

Тагын бер вакыйга. Шулай бервакыт бертөркем Аллаһка ышанмаучылар имам Әбү Хәнифәдән: *“Барча нәрсәне барлыкка китерүче Аллаһка нинди дәлил бар?”* – дип сораганнар. Имам Әбү Хәнифә: *“Торып торыгыз әле, минем уй-фикерем гаҗәеп бер нәрсә белән мәшгуль”* – дигән. Болар: *“Нинди нәрсә белән?”* – дип сораганнар. Имам: *“Елгадан бер зур кораб барадыр, ул төрледән-төрле товар һәм җиһазлар белән төялгән. Әмма аның белән беркем дә идарә итми, хәтта капитаны да юк, ул үзе кайда кирәк шунда йөзә, товарларын үзе төйи һәм бушата.”* Шуннан бу кешеләр аптырап: *“Җүләрләндеңме әллә?*” – дигәннәр. Имам: *“Нигә алай дисез?”* – дип сораган. Болар: *“Акылы урынында булган кеше мондый хәлгә ышана мени?!”* – дигәннәр. Шуннан имам Әбү Хәнифә болай дигән: *“Ә ничек алайса сез, гаҗәеп тереклек һәм вакыйгалар белән тулган галәм, орбиталар буенча йөрүче планеталар бернинди бар итүчесез һәм идарәчесез үзләреннән-үзләре хәрәкәтләнәләр дип ышанасыз?!”* – дигән. Шуннан инде бу кешеләр үзләренең акылсызлыклары өчен бер-берләрен шелтәләргә тотынганнар.

Бер кешедән сораганнар: *“Син ничек Раббыңны таныдың?”*. Ул болай дигән: *“Карагыз әле хатын-кызның карынына эләккән орлыкка – Аллаһ Тәгалә бу орлыктан оешкан кан ясый, аннан ит кисәге итә, һәм ахырдан бөтен әгъзалары үз урынында булган камил кыяфәттәге кешене барлыкка китерә! Аның ишетү өчен колаклары, күрү өчен күзләре, үзенә файдалы нәрсәләргә күрсәтүче акылы, тотып эшләү өчен ике кулы, басып йөрү өчен ике аягы, һәрберсе үз урынына кирәк булган башка әгъзалары бар. Шулай ук аның, аңа кирәк булган файдалы матдәләр керсен өчен һәм, киресенчә, зарарлы матдәләр чыксын өчен тишемнәре дә бар. Гаҗәеп иҗатлык бит бу! Әгәр дә җир йөзендәге барча кешеләр җыелып, әлеге катлаулы процесслар аша шундый камил рәвештәге бер кешене бар итәргә теләсәләр – һичнәрсә дә булдыра алмаслар иде! Бу әлбәттә, кешене бар итүче, һәрнәрсәгә кодрәтле бөек Аллаһка дәлилдер!”*

Әгәр дә Коръәнгә күз салсак – кешенең барлыкка килү процессын Аллаһ Тәгалә төрле алымнар белән аңлатып, дәлил итеп күрсәтә.

Тагын бер кешедән сораганнар: *“Син ничек итеп Раббыңны таныдың?”*. Ул: *“Ният һәм омтылышларның үзгәрүе аша”* – дигән. Ягъни кайчакта шулай була: кеше бернинди икеләнүсез нәрсәдер эшләргә тели, инде эшлим дигәндә генә, кисәк кенә аның нияте башкага үзгәрә, хәттә ул бу эшен үзенә зыянлы итеп күрә башлый. Әлбәттә әлеге ниятләрнең һәм омтылышларның үзгәрүе, кешенең тәне белән идарә иткән кебек, аның калебенә дә юл күрсәтүче Раббысы булуын күрсәтә. Чөнки кешенең бу эшендә ул аңлап-белеп бетермәгән зыян булуы мөмкин. Ә инде Раббысы аңа җиңеллек теләп һәм мәрхәмәтлелек күрсәтеп, иманын һәм динен саклап, аны бу омтылышыннан кайтара. Кеше моны сизмәскә дә мөмкин. Аллаһ Тәгаләдән барча эшләребездә хәерле җиңеллек сорыйбыз!

Бер кешедән сораганнар: *“Син ничек Раббыңны таныдың?”*. Ул: *“Күпме тапкыр мин кайгыда һәм сагышта булдым, ә Аллаһ бу сагышларымны чыгарды, күпме тапкыр авырту булдым, Аллаһка дога кылдым һәм Ул миңа шифа бирде, ярлы идем – мине баетты, адашуда идем – йомшаклык күрсәтте һәм туры юлга чыгарды, ә бу бит минем берүзем белән генә түгел – исәбе-хисабы булмаган башка күп кешеләр белән дә шулай ук булды, әлбәттә, болар аша мин Аллаһның кодрәтен һәм рәхмәтен таныдым”* – дигән.

Тагын бер кешедән сораганнар: *“Син ничек итеп Раббыңны таныдың?”*. Ул әйткән: *“Мин тирә-юньгә күз салдым һәм шуны күрдем – золымлык кылучы явыз кешеләрнең ахыры һәрвакыт аянычлы тәмамланды һәм алар хурлыклы хәлдә вафат булдылар, һәм киресенчә, яхшылык кылучыларның ахыры мактаулы булды. Шулай итеп, Раббыларын танысыннар, Аның берүзенә генә гыйбадәт кылсыннар һәм түбәнчел булсыннар өчен, гыйбрәт итеп, Аллаһ һәркайсына тиешле җәзасын бирде”*.

Тагын бер кешедән сораганнар: *“Син ничек итеп Раббыңны таныдың?”*. Ул болай дигән: *“Аллаһ Тәгалә тереклеккә Үзенең нигъмәтләрен иң кирәкле вакытта һәм аларның моңа мохтаҗлыклары зур булганда бирә. Мисал өчен, яңгыр – Аллаһ Тәгалә аны тереклек суга мохтаҗ булганда яудыра һәм инде су күп җыелып кешеләр хафалана башласалар, яңгырны туктата. Кешенең яки җәмгыятьнең тормышында берәр нинди кризис булса, аның иң кыен вакытында Аллаһ җиңеллек җибәрә. Шулай ук, кешенең төрле әгъзалары – Аллаһ Тәгалә боларны кешегә әкренләп кенә, тиешле*

*вакытында бирә.* [Мисал өчен, тешләр – бала ана сөте белән генә тукланганда әле аның тешләре булмый, чөнки әлегә аларга хаҗәте юк, ә инде ул сөттән кала башка ризыкка мохтаҗ була башлагач, тешләре чыга башлый. [Тәрҗемәчедән]. *Мондый нәрсәләр очраклы рәвештә үзлегеннән була алырмы?! Әллә болар барысы да гыйбадәткә лаеклы, мактаулы Раббылары кайгыртуы сәбәплеме?!”.*
Шуны белү кирәк – кешеләрнең нәрсәгә булса да мохтаҗлыклары күбрәк булган саен, ул әйбер һәрвакытта күп була яки аны табу җиңел. [Мисал өчен, һава яки су – һава суламыйча яки су эчмичә беркем дә тора алмый, шуңа күрә алар тереклек булган һәр җирдә дә бар. [Тәрҗемәчедән]. Ә инде кешеләрнең Раббыларын тануга мохтаҗлыклары башка бөтен нәрсәдән дә өстен тора, шуңа күрә Аллаһ Тәгалә Үзенең киң рәхмәте аша бу юлны табу ишекләрен ачкан һәм җиңеләйткән, дәлилләрен ачып куйган. Ягъни ишетә, күрә һәм фикерли белгән кешегә моны тану бик җиңел.

Тагын бер кешедән сораганнар: *“Син ничек итеп Раббыңны таныдың?”*. Ул әйткән: *“Бала ана карынынннан чыкканда әле берни дә белми, әмма Аллаһ аңа өйрәнү һәм гыйлем алу инструментларын биргән, сәбәпләрен җиңеләйткән. Кеше гомере буе укый, өйрәнә, хәтта дин мәсьәләләрендә хикмәтле галим була, яки дөнья белән бәйле берәр нәрсә өйрәнсә, гаҗәеп нәрсәләр уйлап табучы остага әйләнә. Һәм ни гаҗәп – тактаны язып тутырсаң, анда башка нәрсә язып өчен алдан язганны сөртергә кирәк, ә кешенең калебе һәм акылы бертуктаусыз нәрсәдер өйрәнә, хәтта никадәр күбрәк өйрәнгән саен, акылы ныграк һәм хәтере яхшырак, фикерләү сәләте тирәнрәк була. Моңа кешенең үзенең кодрәте җитәме?! Әллә бу Аллаһның берлегенә, бөеклегенә һәм камиллегенә бер зур дәлилме?!”.*

Шулай бер кешедән сораганнар: *“Син ничек Раббыңны таныдың?”*. Ул әйткән: *“Карагыз әле җиргә чәчә торган орлык бөртегенә һәм җимеш төшенә – алардан пальма агачы һәм бик күп төрле башка агачлар үсеп чыга, төрледән-төрле бик тәмле җиләк-җимешләр, игеннәр пәйда була. Шулар белән кешеләр үзләре һәм аларның маллары туклана. Ә бит бу процесс, кешеләрнең мохтаҗлыклары чамасына, елдан-ел кабатланып килә, хәтта запаска калдырырга һәм киләсе елга утыртырга да кала. Әллә бу Аллаһның барлыгына һәм кодрәтенә, Үзенең колларын кайгыртуына ачык дәлил түгелме?!”.*

Әлеге акыл дәлиленә Аллаһ Тәгалә Коръәндә дә игътибарны юнәлтә: **“Шиксез, Аллаһ Тәгалә орлыкларны һәм җимеш төшләрен яручы, җиргә салынган орлыкны үстерүче”.** (“Әл-Әнгәм” сүрәсе, 95-нче аять). Шулай ук: **“Күрәсезме җиргә утырткан орлык төшләрен? Сезме аларны үстерәсез, әллә Безме үстерүче?”.** (“Әл-Вакыйга” сүрәсе, 63-64 нче аятьләр). [Әгәр дә фикерләп карасак – без, кешеләр, сәбәбен генә кылабыз, ягъни орлык бөртеген җиргә салып куябыз, өстенә су сибәбез һ.б. Ә кем шул орлыкны ярып, аның эченнән үсентене җир өстенә тартып чыгара һәм үстерә? Әлбәттә, галәмнәр Раббысы Аллаһ Тәгаләдер! [Тәрҗемәчедән].

Мөхәммәд пәйгамбәргә ﷺ бик тиз иман китергән бер кешедән сораганнар: *“Сине нәрсә шулай тиз иманга китерде?”*. Ул әйткән: *“Мин шәригатьтә әмер ителгәнне күрдем, һәм минем акылым “Эх, бу әйбер әмер ителмәгән булса иде” – дип әйтмәде. Киресенчә, берәр тыелган әйбер килсә – “Эх, бу тыелмаган булса иде” – димәде”.*

Ягъни, әлеге кеше үзенең якты фикере һәм ныклы акылы белән Мөхәммәд пәйгамбәрнең ﷺ дөреслеген аңлаган, чөнки ул әмер иткән нәрсәләрдә кешегә файда гына, ә тыйганнарда – кешегә зыян бардыр, һәм, шуңа күрә, кешенең табигый халәте һәм чиста акылы моның белән берсүзсез килешә.

Тагын бер кешедән сораганнар: *“Син ничек итеп Раббыңны таныдың?”*. Ул: *“Аллаһ Тәгалә яраткан яхшы эшләрне үтәгәндә күңелемдә һәрвакыт тынычлык һәм җиңеллек тойдым, ә инде Аллаһ ратмаган гамәлгә керсәм – күңелемдә һәрвакыт тынычсызлык һәм авырлык булды”* – дигән.

Ягъни бу калеб һәм күңел ягыннан дәлил. Чынлап та, әгәр кеше берәр нинди яхшы гамәл кылса – иманы арта, күңелендә иркенлек һәм рәхәтлек сизә, әгәр инде нәфесенә бирелеп берәр нинди начар гамәл кылса – иманы зәгыйфьләнә, кәефе төшә. Әлбәттә, бу – кешене Раббысын танырга китерергә тиеш.

Бер кешедән сораганнар: *“Син ничек итеп Раббыңны таныдың?”*. Ул әйткән: *“Мин кешеләрнең мал табу юлларын карадым – бар шундый кешеләр, аның байлыгы, өйләре һәм кәсеб итү чыганаклары күп, ләкин аның күңеле байлыгына бәйләнгән, ул тулысы белән үзенә һәм мөмкинчелекләренә таяна, һәм шулай килеп чыга – аның кәсебе кысыла башлый, әҗәткә бата, ягъни көткән нәтиҗәсенә ирешә алмый. Шул ук вакытта мин күрдем шундый кешене – аның байлыгы, өйләре юк, ләкин Аллаһ Тәгалә аңа ризык табу юлларын җиңеләйтә һәм булган малында бәрәкәт бирә, шуңа күрә, алдагы кеше белән чагыштырганда, аның күңеле дә күпкә иркен һәм тыныч, тормышы сөенечле. Чөнки ул тормышында һәм мал табу юлында үзенең мөмкинчелекләренә һәм башка сәбәпләргә таянмый, ә тулысы белән бу сәбәпләрне бирүче Раббысына таяна, әйе, сәбәпләрен дә кыла, әмма күңеле тулысы белән Аллаһка бәйләнгән. Ә беренче кеше киресенчә, үзенең малына һәм кәсебенә таяна. Ягъни моннан без барлык нәрсә Аллаһ Кулында икәнен таныйбыз”*.

Тагын бер кешедән сораганнар: *“Син ничек итеп Раббыңны таныдың?”*. Ул: *“Мин Аллаһның көннәрне алыштырып торуын күрдем – шул көннәр эчендә кешеләрнең бөеклек һәм түбәнчелек, байлык һәм фәкыйрьлек халәтләре алышынып торды, кайвакытта ниндидер сәбәп аша, ә кайчакта бер сәбәпсез дә шулай булды”* – дигән.

Шулай бер кешедән сораганнар: *“Син ничек Раббыңны таныдың?”*. Ул әйткән: *“Мин Аллаһның сүзләре турында фикерләдем:* **“Җирдәге һәр җан иясен Аллаһ ризыкландырадыр”** (“Һүд” сүрәсе, 6-нчы аять) *һәм тирә-юньгә күз салдым – нинди генә җан иясе булмасын, һәркайсына ризык табу юллары күрсәтелгән һәм җиңеләйтелгән. Мисал өчен, кешеләрне карыйк – кемдер сату-алу, кемдер һөнәрчелек, кемдер җир эшкәртү, кемдер башкаларга хезмәт күрсәтү һ.б. юллар белән үзенә ризык таба. Аллаһның ризыгы вак кына кырмыскалар һәм бөҗәкләр, ерак чүлләрдә һәм тирән океан төбендә яшәүче һәр җан иясенә барып ирешә. Барча тереклек турында кайгыртып торучы Аллаһ Тәгалә һәр кимчелектән пакътыр!”*.

Мондый аерым очракларны һәм мисалларны күп китерергә була, һәм алар акылны бу галәмнең Раббысы булуын һәм Аның берлеген тануга китерә. Әгәр дә син җирдәге яки күктәге, эре яки вак, җанлы яки җансыз булган барча тирә-юньгә күз салсаң, барлык процесслар төгәл законнарга һәм тәртипкә буйсынылган, һәрбер тереклек аңа яшәеш

өчен кирәк булган әйберләргә юнәлтелгән һәм кайгыртылганлыгы турында фикерләсәң, бу галәмнең Патшасы, һәрнәрсәгә көче житүче бөек Раббысы бар икәнен күрерсең. Аңа барчасы буйсынган, Аның әмереннән һичкем дә чыга алмый, Аннан ярдәм булмаса, беркемнең дә бернәрсәгә дә көч-куәте житми. Аллаһ әйткәнчә: **“Һәм җирдә – инанган кешеләр өчен билгеләр бардыр.”** (“Әз-Зәрият” сүрәсе, 20-нче аять).

Шулай ук, Аллаһның камил шәригате турында фикерләп кара. Аның хәбәрләре дөрес, хөкемнәре гадел, әмерләре төгәл, яхшылык һәм чисталык боерылган, начарлык һәм бозыклык тыелган. Заманнар үтә, җәмгыять һәм цивилизацияләр алышына – Аллаһның шәригате үзгәрмичә кала бирә, ягъни һәр вакытка, һәр халәткә туры килә. Гадел булган, тирән фикерләп карый белгән кеше аңлый – башка бернинди кануннар һәм җәмгыять системалары Аллаһ куйган кануннар белән ярыша алмый, хәттә киресенчә, әгәр дә берәр хөкем Аллаһның хөкемнәренә каршы килә икән, иртәме-соңмы бу аерым шәхеснең һәм җәмгыятьнең тормышында төрле проблемаларга китерә.

Әлбәттә, болар барысы да Аллаһның бөеклегенә, кодрәтенә, һәрнәрсәне чолгап алган белеменә һәм хикмәтенә ачык дәлилдер: **“Бар нәрсәне камил кылган Аллаһның иҗаты шундыйдыр”.** (“Ән-Нәмел” сүрәсе, 88-нче аять), **“Инанган кешеләр өчен Аллаһның хөкеменнән дә яхшырак хөкем булырмы?”.** (“Ән-Мәидә” сүрәсе, 50-нче аять).

## **<u>ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК.</u>**

### **<u>Аллаһның барлыгы – бар нәрсәдән дә ачыграк.</u>**

Пәйгамбәрләр үзләренең өммәтләрен дингә чакырганда да акыл дәлилләренә игътибар бирделәр, шулар аша Аллаһның барлыгына бернинди дә шик була алмый, бу мәсьәлә бөтен нәрсәдән дә ачыграк икәнен исләренә төшерделәр. Шуңа күрә һәрбер пәйгамбәр әйтә торган булган: **“Әллә җирне вә күкләрне бар кылучы Аллаһка шик тотасызмы?”.** (“Ибраһим” сүрәсе, 10-нчы аять). Чынлыкта бу инкяр итү соравы, чөнки Аллаһның барлыгын кеше акылы һәм табигый халәте белән яхшы белә. Барча галәмне, барча тереклекне һәм җансыз әйберләрне юктан бар кылып, бу гаҗәеп системаны таркалмасын, юкка чыкмасын өчен кайгыртып торучы бар – Ул, әлбәттә, Аллаһ Тәгалә. Әлеге мәсьәләне бары тик акылында гаеп булган, калебе һәм табигый халәте авышкан, күңелен төрле фәлсәфә фикерләр белән тутырган кеше генә кире кагыр.

Пәйгамбәрләр җибәрелгән кавемнәрнең күбесе Аллаһ Тәгаләнең барча нәрсәне юктан бар кылучы бердәнбер Галәмнәр Раббысы булуын таныдылар, ягъни инкяр итмәделәр, ләкин алар Аллаһ белән беррәттән башка нәрсәләргә гыйбадәт кыла иделәр, мисал өчен, Нух, Һүд, Салих һ.б. пәйгамбәрләрнең кавемнәре. Аллаһның барлыгын инкяр итүчеләр сирәк иде, мәсәлән шулардан, Мисырда хакимлек иткән Фиргавен. Коръәндә аның сүзләре китерелә: **“Галәмнәрне бар кылучы ул нинди зат?”.** (“Әш-Шугара” сүрәсе, 23-нче аять). Шулай ук: **“Фиргавен әйтте: “Ий җәмәгать, сезнең өчен миннән башка иләһ бар дип белмимен”.** (“Әл-Къасас” сүрәсе, 38-нче аять). [Әмма

Фиргавен теле белән Аллаһны инкяр итсә дә, хәтта үзен Аллаһ дәрәҗәсенә күтәрсә дә, күңеле белән ул Аллаһның барлыгына, Аның Галәмнәр Раббысы булуына ышана иде. Аллаһ Тәгалә моны Коръәндә житкерә: **“Алар бу могҗизаларның Аллаһтан икәнлеген инкяр иттеләр, ләкин күңелләре белән моны белә иделәр, золымлык вә тәкәбберлек белән”.** (“Ән-Нәмел” сүрәсе, 14-нче аять). Чөнки бу, алдан әйткәнчә – һәркемнең тумыштан булган табигый халәте. Әлеге аятьтән кешенең Аллаһ Тәгаләне инкяр итүенең сәбәбе – золымлык һәм тәкәбберлек икәнен күрергә була. [Тәрҗемәчедән].

Пәйгамбәрләр кавемнәренә Аллаһның барча нәрсәне юктан бар кылуы, бердәнбер Галәмнәр Раббысы булуы, бөтен нигъмәтләрне биреп торуы турында исләренә төшерүләренең асылы – барча гыйбадәтләрне бер Аллаһка гына юнәлтеп, Аңа шөкер кылырга, Аны зекер итергә, хәмед-сәнәләр әйтеп зурларга кирәклеген аңлату иде: **“Аллаһка гына гыйбадәт кылыгыз, Аңардан башка сезгә гыйбадәткә лаеклы илаһ юктыр”.** (“Әл-Мөэминүн” сүрәсе, 23-нче аять).

<u>**Алдан яшәгән халыклар белән булган вакыйгалар.**</u>

Аллаһ Тәгалә Коръәндә элекке заманда яшәп узган халыкларның халәтен китерә – алар көферлектә иделәр һәм пәйгамбәрләрне инкяр иттеләр, шуның сәбәпле, Аллаһ тарафыннан төрле газабларга дучар булдылар. Кемнәрдер моны үз күзләре белән күрде, ә кемнәргәдер буыннан-буынга хәбәр булып барып ирешә. Шуңа күрә, Аллаһ Тәгалә әлеге акыл дәлиленә игътибарны юнәлтә: **“Сез дөньяда үзләренә золымлык кылган кавемнәр торган урында тордыгыз, вә аларны ничек газабка тотканыбыз сезгә ачык мәгълүм иде, һәм сезгә мисаллар китердек”.** (“Ибраһим” сүрәсе, 45-нче аять). Шулай ук: **“Әллә алар жир өстендә йөрмиләрме, вә үзләреннән элек һәлак булган кавемнәрнең хәлен күрмиләрме?!”.** (“Әр-Рум” сүрәсе, 9-нчы аять). Һәм шулай ук: **“Без сезнең тирә җирлекләрдәге кавемнәрне һәлак иттек, һәм төрле аять-могҗизалар җибәрдек, бәлки иманга кайтырлар, дип”.** (“Әр-Әхкъаф” сүрәсе, 27-нчы аять).

<u>**Пәйгамбәрләрнең камиллекләре һәм аларның могҗизалары.**</u>

Шулай ук, Аллаһның пәйгамбәрләре турында фикерләп карасак, күрербез – алар кешелек тарихында иң гыйлемле һәм хикмәтле, иң дөрес сүзле, башкаларга карата иң мәрхәмәтле, барча югары әдәп-әхлакка ия булучы һәм барча түбән сыйфатлардан иң ерак кешеләр булганнар. Әлбәттә, мондый кешеләр бервакытта да ялган сөйләмәсләр, шуңа күрә бу аларның Аллаһтан килгән пәйгамбәрләр булуына бер дәлилдер! Шуның өстенә, аларга бирелгән төрле могҗизалар – пәйгамбәрләрнең хаклыкта булуына тагын бер күрсәткеч! Болар барысы да Аллаһны һәм Аның берлеген танырга китерергә тиеш.

<u>**Пәйгамбәрләрнең чакыруы бер булган.**</u>

Нинди генә заманда яшәгән, кайсы гына пәйгамбәрнең чакыруына карасак – һәрберсе Аллаһның берлеген танып, бер аңа гына гыйбадәт кылырга кирәклеген аңлатканнар. Чөнки бу мәсьәлә – иң бөек һәм беренчел. Акыл һәм дин ягыннан камил булган, югары сыйфатларга ия булган калган кешеләр дә Аллаһның берлеген таныйлар һәм

моның белән килешәләр. **“Ошбу Коръән сүзләре Аллаһның аятьләредер, ул аятьләрне Без сиңа хаклык белән укыйбыз, Аллаһтан соң нинди затка иман китерерләр, вә Аның Коръән аятьләреннән соң нинди сүзләргә ышанырлар? Нинди кайгыдыр ялганчы, күп гөнаһлы имансызларга! Аңа укылган Аллаһ аятьләрен ул ишетер, аннан тәкәбберләнеп, ишетмәгәнгә салышып, кабул итүдән баш тартыр, андый кешене рәнҗеткүче газаб белән сөендер”.** (“Әл-Җәсия” сүрәсе, 6-8 нче аятьләр).

**<u>Аллаһның, фәрештәләрнең һәм туры юлдан баручы гыйлем ияләренең шәһадәте.</u>**

Иң бөек шәһадәт бирүче – Аллаһ Тәгалә, Үзе шәһадәт китерә: **“Аллаһ Үзе вә фәрештәләр һәм хакыйкый чын галимнәр: “Кол булырга яраклы илаһ юк, мәгәр Аллаһ үзе генә”, – дип дөреслек белән һәм исбатлау белән шәһадәт бирәләр. Гыйбадәт кылуга лаеклы юктыр һичбер илаһ, мәгәр Аллаһ Үзе генә. Ул бар囊 эштә җиңүче, хикмәт белән эш кылучы”.** (“Әлү-Гыймран” сүрәсе, 18-нче аять).

Аннан соң Аллаһның иң яхшы коллары – барча фәрештәләр, төпле һәм дөрес гыйлемгә ия булучы галимнәр, алардан алдан торучы пәйгамбәрләр һәм рәсүлләр, туры юл имамнары – бөтенесе бертавыштан Аллаһның берлегенә шәһадәт китерәләр.

Әгәр дә син “гыйлемгә ия булдым” дип дәгъва кылган, әмма аның гыйлеме Аллаһның берлеген тануга китермәгән кешене күрсәң, аңларсың – бу гыйлеме аңа бернинди дә файда бирми, хәтта киресенчә, зыян гына сала, калебен тәкәбберлеккә һәм горурлыкка китерә. Чөнки бу гыйлем – пәйгамбәрләргә каршы чыгучылардан калган файдасыз гыйлем: **“Аларга пәйгамбәрләре могъҗизалар вә ачык дәлилләр белән килсәләр – пәйгамбәрләрнең хак сүзләрен һичнәрсәгә санамыйча, үзләрендә булган сукыр белемнәре белән мактанып шатландылар. Һәм соңыннан аларны үзләре мәсхәрә кылган газаб чорнап алды”.** (“Гафир” сүрәсе, 83-нче аять). Ягъни халыкларга пәйгамбәрләр Аллаһтан булган гыйлем белән килгәч, бу халыклар үзләрендә булган матди һәм дөньяви белем белән горурланганнар, пәйгамбәрләргә каршы чыкканнар, Аллаһның аятьләрен мәсхәрә кылганнар, һәм ахыр чиктә, Аллаһ аларга үзләре инкяр иткән газаб җибәреп, аларны хурлыкка салган.

Алар арасында, шулай ук, атеистлар һәм материалистлар булган. Пәйгамбәрләр тәүхид, Аллаһка иман белән килгәч, аларны электән калган хәбәрләргә сукырларча ияручеләр, цивилияциядән артта калучылар дип мыскыллаганнар. Чынлыкта үзләре – акыл ягыннан зәгыйфь, фикерләүгә сәләтсез, алдан яшәгән материалистларның сүзләренә һәм гамәлләренә сукырларча иярүчеләрдән булганнар. Үзләрендә булган матди белем белән горурланганнар, ә бит мондый белем кешенең рухына файда бирми, әгәр дә дөньяви белем дин гыйлеме белән бәйләнештә бармаса, кешегә моннан ахирәттә бернинди дә файда булмаячак, хәттә дөньясы да нык кимчелекле булачак. Шуңа мондый хәлдәге кеше матди гыйлеме белән горурланып, үзенә иң зур зыян сала – Аллаһка, хаклыкка һәм кешеләргә карата тәкәббәрлек күрсәтә, калебләрне һәм әхлакны чистартучы, дөньяны һәм ахирәтне дөресләүче, барча яхшылыкка өндәүче һәм начарлыктан ерагайтучы пәйгамбәрләр алып килгән гыйлемгә каршы чыга, нәфрәт күрсәтә. Шуның өстенә ул, шул матди гыйлеме белән горурланып, башкаларга түбәнсетеп карый, бәлки аларны җәнлекләрдән дә аска куя, ә чынлыкта үзенең

тормышы җәнлек тормышыннан да түбәнрәктер. Мисал өчен, “цивилизацияле” дип аталучы халыкларга гына карыйк – әйе, алар техник һәм башка яктан күпмедер прогресс кичерәләр, әмма бу прогресс һәм цивилизация матди генә, бәлки алар өчен һәлакәт белән яный. Әгәр дә без аларның халәтенә тирәнрәк карасак, күрербез – анда золымлык һәм гаделсезлек, зәгыйфьләрне кыерсыту, алдалау, җинаятьчелек, шул сәбәпле игеннәрне һәм нәселләрне һәлак итү – ахыр чиктә болар барысы да бер-берләре арасында дошманлык һәм нәфрәт таралуга, бер-берләрен җәберләүгә китерә.

Әмма алар, кызганычка каршы, үзләреннән алдан яшәгән халыкларның Аллаһка карышканнары һәм золымлыклары сәбәпле төрле газабка дучар булуларын белсәләр дә, моның белән вәгазьләнмиләр, бәлки киресенчә, тәкәбберлекләрен һәм золымлыкларын арттыралар. Бу дөньяда газабта яшиләр, ахирәттә күпкә катырак газабка юнәләләр. Үзләренең сукыр адашуларында әйләнәләр, түбән һәм кимчелекле “цивилизацияләре” белән горурлаланалар: **“Алар дөнья тереклеге өчен нәрсә кирәк, шуны белерләр, ләкин ахирәттән алар гафилләр”.** (“Әр-Рум” сүрәсе, 7-нче аять).

Аллаһ Тәгалә ачык мисаллар китерә – күңелләр моңа колак салырмы икән?! Үзенең камиллегенә, гаделлегенә һәм хикмәтенә күрсәткечләр куйган – фикерләп карауч булырмы икән?! Әллә калебләр гафиллек һәм тәкәбберлек белән капланганмы?! Җаннар – күзләрне сихерләүче ялтыравык дөнья алдавычларына юнәлгәнме?! **“Залим кешегә кылган явызлыгы үзенә зиннәтле һәм яхшы булып күренде, шул залим, туры юлда булган инсафлы мөэмин белән бертигез булырмы?”** (“Фәтыр” сүрәсе, 8-нче аять). **“Һәм шайтан аларга Аллаһка каршы булган эшләрен изге итеп күрсәтте”** (“Әл-Әнгам” сүрәсе, 43-нче аять). **“Алар Аллаһның вәгазьләрен һәм газаб белән куркытуын оныткач – дөньяви эшләрендә уңышларга юл ачтык, хәтта алар Аллаһ биргән нигъмәт белән шатланыр һәм мактаныр булдылар. Шул вакытта без аларны кисәктән газаб белән тоттык, алар өметсезләнеп хәсрәтләнүчеләрдән булдылар.”** (“Әл-Әнгам” сүрәсе, 44-нче аять).

Әмма инде, Аллаһның берлегенә Аллаһ Үзе шәһадәт биргәненә килсәк – бу барча Изге китапларда килде. Һәрбер пәйгамбәр моның турында сөйләде һәм барчасының да чакыруы әлеге шәһадәтне җиткерү булды. Аларга төпле белем ияләре, туры юл галимнәре, гыйлем һәм иман әһелләре иярделәр, Аллаһның берлеген раслап шәһадәт китерделәр. Шуңа күрсәткеч итеп, Аллаһ тереклектә һәм кешеләрнең үзләрендә төрле билгеләр куйды: **“Төннең вә көннең яратылышы, кояш вә айның төзелеше һәм хәрәкәтләре Аллаһның кодрәтенә һәм берлегенә дәлил вә галәмәтдер.”** (“Фүссыләт” сүрәсе, 37-нче аять). Биек һәм зур галәм, түбән булган җир, барча тереклек, шулар барысы да искиткеч хәлдә бар кылынып, тәртиптә тотылып торулары – Аллаһның берлегенә ачык аять һәм дәлилләр. Тереклектә булган гүзәллек, могҗизалар, гаҗәеп хикмәтләр турында иң оста һәм матур телле кешеләр сөйләсәләр дә – тиешенчә тасвирлап бетерә алмаслар иде!

**Аллаһның һәм Аның рәсүленең башкалардан яшерен булган әйберләр турында хәбәр бирүләре.**

Шәригать текстларында килүче һәм, шулай ук, кешеләр үзләре күреп торган тагын бер дәлил – Аллаһ Тәгалә Коръәндә һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ хәдисләрендә төрле

яшерен булган вакыйгалар турында хәбәр бирүләре. Элек булып узган, хәзерге заманда булып торучы һәм киләчәктә булачак төрле вакыйгалар – һәрберсе ничек хәбәр ителгән шулай булган һәм булып тора. Бу вакыйгаларны аерым төр категорияләргә бүлсәң дә санап бетерүе авыр булыр, ә инде аерым вакыйгалар бигрәк тә күп, барысын да өйрәнү һәм искәртеп үтү өчен китаплар язарга кирәк булыр иде. Әлеге вакыйганың берсе генә чынга ашса да – дәлил кебек җитәр иде, әмма шәригать текстларында алар ничек әйтелгән шул рәвештә бер-бер артлы чиратлашып чынга ашалар, әлбәттә, болар Аллаһның берлегенә һәм аның пәйгамбәренең ﷺ хаклыгына һичшиксез ачык дәлилдер.

**<u>Аллаһ Тәгаләнең барча кешеләрне һәм җеннәрне Коръәнгә тиң булган берәр иҗат китерергә чакыруы.</u>**

Коръәнне укып карасак күрербез – Аллаһ барча кешеләрне һәм җеннәрне әгәр Коръәнгә ышанмасагыз, аңа охшаш яки тиң булган берәр нәрсә иҗат итегез дип чакыру биргән, ләкин, шул ук вакытта, берегез дә моны беркайчан да эшли алмаячак дип искәртеп тә узган. Бу чакыру һәрбер заманда һәм урында кала бирә, әмма Мөхәммәд пәйгамбәргә ﷺ карышучылар, һәрвакытта да үзләренең дошманлыкларын күрсәтергә, төрле мәкерлекләр кылырга тырашсалар да, бу чакыруга җавап биргәннәре юк һәм җавап бирә алмаячаклар да! Әлбәттә, бу күрсәтәдер – Коръән кеше сүзе түгел, бәлки – галәмнәр Раббысы Аллаһның сүзе, гадел кеше өчен бу шулай ук бер дәлил.

**<u>Мөхәммәд пәйгамбәрнең ﷺ чакыруының күркәм нәтиҗәләре.</u>**

Аллаһ Тәгаләнең берлегенә бер дәлилләрдән булып – Мөхәммәд пәйгамбәрнең ﷺ чакыруыннан үсеп чыккан һәм таралган төрле күркәм нәтиҗәләр тора. Ул килгән вакытта халыклар гыйлемсезлектә, ширек [Аллаһтан башка затларга гыйбадәт кылу] һәм төрле начар гадәтләрдә иделәр. Аллаһ Тәгалә аларны үзенең пәйгамбәре ﷺ аша адашудан – хак юлга, гыйлемсезлектән – гыйлем яктылыгына чыгарды, әхлаклар һәм гамәлләр төзәлде, җир – туры юл һәм дөреслек белән тулды, мәрхәмәтлелек һәм гаделлек таралды, уңышка ирешү һәм котылу юллары ачылды. Калебләргә файдалы гыйлем, дөрес инану үтеп керде, ислам дине бөтен дөнья буйлап таралды, начарлыкка авышмаган туры күңелләр бу динне якын күрделәр һәм кабул иттеләр, ялган һәм батыл ышанулар юкка чыкты.

Әлеге дингә ныклап ябышып яшәгән вакытта мөселманнар барысыннан да өстен иделәр, ә инде алар арасына төрле ялгыш ышанулар, начар әхлак һәм гамәлләр үтеп кергәч, ягъни Аллаһның кануннарына салкын карый башлагач – хәл үзгәрде, мөселманнар диннәре белән дә, дөньялары белән дә артта калдылар, нык түбән тәгәрәделәр. Шуннан күрәбез, әлеге шәригать – бар нәрсәне белүче һәм хикмәт иясе, һәрнәрсәгә кодрәте җитүче Аллаһтан иңгән һәм Ул Үзенең диненә ярдәм бирә. Барча яхшылык Аллаһтан килгән гыйлемдә җыелган – нинди генә хәбәре килсә дә, сәламәт акыл һәм хис-тойгылар моны дөрес дип таба. Аның кануннары шундый камил системага салынган – дөньядагы иң укымышлы һәм гыйлемле кешеләрне бергә җыйсаң да, мондый нәтиҗәгә якын да килә алмаслар иде. **“Китергән хәбәрләре дөреслек белән һәм хөкемнәре гаделлек белән Раббыңның сүзләре тәмам булды.”** (“Әл-Әнгам” сүрәсе, 115-нче аять).

## Аллаһ шәригатенең камиллеге.

Аллаһ Тәгаләнең берлегенә, Аның рәсүленең хаклыгына бер дәлилләрдән булып шәригать системасының камиллеге тора – ул бөтен яктан тәртипкә салынган, хәбәрләре чынбарлык белән туры килә һәм дөрес, хөкемнәре гадел. Кешеләр күпме генә тырышсалар да, мондый күркәм, һәр заманга һәм вакытка туры килгән, кешеләрнең һәм җәмгыятьнең тормышын бөтен яктан дөресләүче, һәм, шул ук вакытта, бер хөкеме дә башка хөкемнәренә каршы килмәгән кануннар системасын уйлап чыгара алмыйлар. Бу шәригатьне тирәнрәк өйрәнгән саен күрәсең – хәбәрләре моннан да дөресрәк һәм калебләргә файдалырак, хөкемнәре яхшырак, гыйбадәтләрне һәм мөгамәләтләрне бөтен яктан дөресләүче башка бернинди дә кануннар җыелмасы юк һәм аңарга якын да тормый: **“Әллә алар Коръәннең мәгънәсен фикерләп, уйлап карамыйлармы? Әгәр бу Коръән Аллаһтан башкалардан булса, әлбәттә, анда капма-каршылыкларны күп табар иделәр.”** (“Ән-Нисә” сүрәсе, 82-нче аять). Шуңа күрә, Аллаһ Тәгалә акыл ияләрен фикерләп карарга чакыра – бу Коръән бары Аллаһтан гына була ала, ул тулысы белән хак, аңарга каршы килгән башка фикерләр һәм хөкемнәр – батыл һәм кимчелекле: **“Сиңа иңдерелгән Коръән Раббыңнан килгән хак китап булганын, вә ул Коръән һәр эштә җиңүче вә мактаулы булган Аллаһ юлына күндерүче икәнлеген гыйлем ияләре белерләр.”** (“Сәбә” сүрәсе, 6-нчы аять). Әлеге дин дөреслек белән килде һәм дөресне сөйләүчеләрне яклады, ялганны һәм ялган сөйләүчеләрне фаш итте, Аллаһның, аннан Аның колларының хокукларын үтәүдә барча гаделлекне торгызды, золымлыкны, начарлыкны һәм бозыклыкны тыйды. Асылы – иманда, ихласлыкта, Бер Аллаһка гыйбадәт кылуда төзелде, күпиләһлектән һәм башка затларны Аллаһка тиңләүдән кисәтте. Ата-ананы кайгыртырга һәм аларга мәрхәмәтле булырга, туганлык җепләрен ныгытырга, күршеләргә, фәкыйрь-мескеннәргә, хәтта җәнлекләргә – барча җан ияләренә карата йомшаклык күрсәтергә һәм яхшылык кылырга чакырды, Аллаһның яхшылык кылучыларны сөйгәнен җиткерде. Вәгъдә һәм килешүләрне үтәргә өндәде, киресенчә, аларны бозудан һәм сүздә тормаудан кисәтте. Дин һәм дөньялык гамәлләрендә файдалы эшләр кылырга, әмма барчасында да эшләгән гамәлләреңә түгел, ә тулысы белән Бер Аллаһка гына тәүәккәл кылырга кирәклеген аңлатты. Бөтен яхшы һәм күркәм нәрсәләрне хәләл, бөтен начар һәм түбән нәрсәләрне хәрәм кылды. Файдалы булган әйберләргә юллар күрсәтте һәм зарарлы булган нәрсәләрдән юлларны япты. Көенечле вакыйгаларда сабыр булырга, сөенечле вакытта шөкер итәргә чакырды. Хафаланудан, көчсезлек һәм куркаклык күрсәтүдән, түбән әдәп-әхлактан кисәтте, көчле һәм кыю булырга, саф күңеллеккә һәм күркәм әхлакка өндәде. Нәрсә генә әмер ителгән булса да –сәламәт акыл ияләре бу әмер ителгәнне дөрес һәм гадел дип тапты, нәрсә генә тыелган булса да – бу тыелганны түбән һәм ямьсез диде. Калебләрне чистартучы дөрес ышануларны аңлатты һәм боерды, барча сүзләрне һәм гамәлләрне, дин һәм дөнья эшләрен шуңа нигезләргә кирәклеген җиткерде. Аерым шәхеснең тормышын һәм җәмгыятьнең хәлен, гыйбадәт һәм мөгамәләтләрне дөресләүче бөек әхлак һәм изге гамәлләр белән килде. Нинди генә яхшылык һәм нинди генә начарлык булмасын – һәрберсенә әлеге диндә күрсәтмә бар. Нинди генә хәбәре һәм хөкемнәре, нигезләре һәм кагыйдәләре булмасын – берсе дә кешеләрнең тәҗрибә аша расланган дөрес гыйлемнәренә һәм сәламәт акылга каршы килми. Әгәр дә кешеләрнең диннәре һәм дөньялыклары Аллаһ кушмаган башка тәгълиматләргә, башка кануннарга һәм

хөкемнәргә нигезләнә икән – алар кешегә зыян, җәмгыятькә таркаулык китерә, ахыр чиктә кешелек тормышы бозыла һәм аяныч белән тәмамлана. Чөнки әлеге диннең хөкемнәре – һәрнәрсәдән хәбәрдар, ачык һәм яшерен нәрсәләрне белүче, һәрбер эшендә җиңүче, хикмәт Иясе, барча тирәлекне гыйлеме һәм рәхмәте белән чолгап алган галәмнәр Раббысы Аллаһ Тәгаләдән киләдер. Кем бу дингә ныклап ябышты – шул бәхеткә һәм уңышка, әҗер-савапка һәм котылуга иреште. Әлбәттә болар барысы да Аллаһның берлегенә һәм бөеклегенә, хакимлегенә һәм хикмәтенә, мактаулыгына һәм юмартлыгына ачык дәлилдер: **“Алар укый-яза белмәгән, аның турында Тәүратта һәм Инҗилдә хәбәрләр килгән пәйгамбәр рәсүлебез – Мөхәммәдкә иярерләр, ул аларны гөнаһлы эшләрдән тыяр вә саваплы эшләргә өндәр, яхшы-пакъ нәрсәләрне аларга хәләл кылыр, зарарлы-пычрак нәрсәләрне хәрам кылыр, аларда булган авырлыкны вә диннәрендәге каты хөкемнәрне бетерер, рәсүлгә ышанып, аны хөрмәтләсәләр вә аңа ярдәм итсәләр һәм ул китергән һидәят яктылыгы булган Коръән хөкемнәренә иярсәләр, алар – өстенлек табучылар.”** (“Әл-Әгъраф” сүрәсе, 157-нче аять). **“Аллаһ Тәгалә – һәр эштә гадел булырга һәм яхшы эшләр кылырга вә якыннарның хакын үтәргә боерадыр, вә Аллаһ сезне тыядыр бозык хәрам эшләрдән вә шәригать белән туры килмәгән бидгәт гамәлләрдән, хаксыз золым итүдән. Аллаһ сезне вәгазьли, бәлки вәгазьләнерсез!”** (“Ән-Нәхел” сүрәсе, 90-нчы аять).

## <u>Пәйгамбәрләрнең хаклыгы.</u>

Аллаһ Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә бер дәлилләрдән булып пәйгамбәр һәм рәсүлләрнең хаклыгы тора, шуңа күрә аларны хөрмәт итәргә һәм аларның юлына иярергә кирәк. Имам ибн Тәймия әйткән: *“Пәйгамбәрләргә бирелгән аять һәм могҗизалар – алардан кала башка беркемгә дә бирелмәгән. Акыл ияләре беләләр – пәйгамбәрләрдән кала мондый могҗизаларга беркем дә ия була алмый. Кавемнәренә китергән могҗизаларны күреп бу халыклар кайсылары иманга килде, кайсылары ялганга чыгарды – ахыр чиктә иман ияләре котылу һәм уңышка ирештеләр, ялганга тотучылар һәлак булдылар. Пәйгамбәрләрдән кала башка кешеләр белән мондый вакыйгалар булмады. Мисал өчен, Нух пәйгамбәр вакытында бөтен Җир өстен су басты, Нух пәйгамбәр һәм аның иярченнәреннән кала башка кешеләр һәлак булдылар, мондый хәл башка беркем белән дә кабатланмады. Яки биек баганалардан төзелгән Ирам шәһәрендә яшәүче Гәд кавеме – нинди генә куәтле булуларына һәм нинди бөек биналар төзүләренә карамастан – тиз исүче үткен җил белән һәлак булдылар. Яки Салих пәйгамбәр кавеме – көчле тавыш чыгып, Лут пәйгамбәр кавеме – торган җирләре белән өскә күтәрелделәр һәм кирегә әйләнеп капландылар, артларыннан ташлар җибәрелде, ягъни шулай һәлак ителделәр, бары Лут пәйгамбәр генә иярченнәре белән котылды. Яки Муса пәйгамбәр һәм фиргавен кавеме – беренчеләр диңгез ачылып аның төбеннән исән-имин үттеләр, икенчеләре артларыннан куып килеп, диңгез ябылып, шунда баттылар. Акыл ияләре беләләр – мондый вакыйгалар бары пәйгамбәрләр заманында гына булган, башка вакытларда кешеләр – кемдер вәба авыруыннан, кемдер башка авырулардан яки башка сәбәпләрдән вафат була, кешеләр моны күреп ияләнсәләр дә, болар да Аллаһның бер билгеләре, әмма пәйгамбәрләр заманында булган могҗизалар башка вакытта беркем белән дә кабатланмый.*

*Тагын бер мисал китерик – Мәккәдә урнашкан Кәгъбәне. Бу – таштан төзелгән бер бина, бушлыкта һәм бернәрсә дә үсми торган корылыклы җирдә барлыкка килгән. Аны беркем дә сакламый, тирәсендә бернинди бакчалар да һәм кешенең күзләрен җәлеп итәрлек бернәрсә дә юк. Ләкин аны Аллаһ Үзе саклый – кешеләр бу җиргә түбәнчелек белән, күңелләре тулып, дөньяның бөтен җирләреннән килергә омтылалар, аны хөрмәтлиләр, шул ук вакытта, аларны бу җиргә бернинди дә дөньялык омтылышы тартмый, һәм бу хәл инде ничә мең еллар дәверендә дәвам итә. Ни өчен шулай? Чөнки Аллаһ – бу җирлекне сайлап алган, күңелләргә аңа карата ярату һәм хөрмәт салган. Җир шарында башка бернинди дә мондый урын юк, һәм бу хәл фикер ияләрен таңга калдыра.*

*Шулай ук, Фил вакыйгасын да беләбез – араларында фил булып гаять зур гаскәр Кәгъбәне җимерергә дип юнәлде, ләкин аңа якынайгач, фил туктап калды һәм юлны дәвам итергә киреләнде, башка якка тартып карадылар – ул якка барды, әмма Кәгъбә ягына боргач, атламады. Аннан Аллаһ бу гаскәргә диңгез ягыннан кошлар җибәрде, таш яудырып бу гаскәрне һәлак итте. Ягъни, Аллаһ – Үзе сайлап алган һәм пәйгамбәрләр төзегән йортны шулай саклады, мондый вакыйгалар калган заманнарда кабатланмады.*

*Бу могҗизалар һәм вакыйгалар – пәйгамбәрләрнең хаклыгына ачык дәлилләр. Аллаһ шул рәвешле пәйгамбәрләргә иман китерүчеләрне һәм ялганга тотучыларны аерды, Аның җирдә урнаштырылган үзгәрмәс кануны шундый булды.*

*Бу тарихи вакыйгалар буыннан-буынга тапшырылган һәм кешеләр арасында таралган. Кешелек җәмгыяте белә – болар пәйгамбәрләрнең могҗизалары һәм аларны ялганга тоткан кавемнәргә килгән тиешле җәза. Шулай ук, Коръән – Мөхәммәд пәйгамбәр ﷺ килгән вакыттан ничә йөз еллар дәвамында килүче бер могҗиза. Шул заманда ук инде Аллаһ Тәгалә Үзенең Сүзләрен иңдерде:* **“Әйт: “Әгәр кешеләр һәм җеннәр барчасы җыелып бер-берсенә ярдәмләшеп Коръәнгә охшаш бер китап иҗат итәргә тырышсалар да, һич тә иҗат итә алмаслар.”** (“Әл-Исра” сүрәсе, 88-нче аять). *Ул вакытта да һәм киләчәктә дә җир йөзендә күп халыклар барлыгын һәм булачагын белеп, Мөхәммәд пәйгамбәр ﷺ катгый рәвештә бу сүзләрне үзенең заманында ук игълан итте. Бу пәйгамбәрләрдә генә була торган нык дәлил. Коръәнгә иярүчеләр дә һәм аңа каршы чыгучылар да, гарәпләр һәм башка халыклар да инде ничә гасырлар дәвамында бу Китапны укыйлар, әмма бер халык та Коръәнгә тиң, хәттә әз генә дә охшаш булган, хөрмәтләнгән, шулай күп һәм еш укыла торган бер китап та иҗат итә алганы юк. Нинди генә югары нотык белән язылган шигырь, әсәр, фәнни тикшеренү яки ниндидер хикмәтләр тупланган китап булмасын – берсе дә Коръәнгә якын да килми. Коръәннең Сүзләре – могҗиза, тәртибе һәм төзелеше – аерым бер могҗиза, хәбәрләре – тагын бер могҗиза, әмерләре һәм тыюлары – могҗиза, вәгъдә һәм кисәтүләре – могҗиза, калебләргә һәм күңелләргә үтеп кереп, аларга нык тәэсире – могҗиза, хәтта башка телләргә тәрҗемә ителеп мәгънәләре тапшырылуы – шулай ук могҗиза, башка бернинди китапны да Коръән белән чагыштырып булмый.”*

Пәйгамбәрләр (Аллаһның аларга сәламе булсын) алып килгән барча гыйлем – кешеләргә бу дөньяда һәм ахирәттә файда китерүче хаклык, аңа каршы килгән

фикерләр – батыл һәм кимчелекле: **“Бәлки хаклык белән Коръән килгәч, алар аны ялган диделәр, менә хәзер инде буталчыклы хәлгә төштеләр.”** (“Къаф” сүрәсе, 5-нче аять). Шулай ук, кешеләрнең, аеруча пәйгамбәрләрнең, күңелләренә салынган табигый халәт – Аллаһның барлыгына һәм берлегенә ышану – бер дәлил. Мөхәммәд пәйгамбәр ﷺ кешеләр арасында иң гыйлемле һәм хикмәтле, аз сөйләүчән, әмма иң оста телле, иң яхшы аңлатучы кеше иде, мөселманнар аның пәйгамбәрлегенә шаһит китерәләр, бу шулай ук бер дәлил.

## Йомгаклау.

Шулай итеп, барча тереклек һәм вакыйгалар – Аллаһ Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә, бердәнбер галәмнәр Раббысы булуына ачык күрсәткечләр: Кем барча нәрсәне юктан бар кылды? Кем барча мәхлукат белән идарә итә? Кем күкләрне һәм җирләрне төзеде һәм аларны саклап тора? Кем адәм баласын бер тамчыдан бар итте һәм шул тамчыдан бар булган җан иясе Аллаһка карыша?! Кем терелтә һәм вафат кыла? Кем бәхетле яки бәхетсез итә? Кем хаклыкка буйсынмаган кавемнәрне һәлак итте, пәйгамбәрләрне һәм аларга иярүчеләрне коткарды? Боларның барысында да фикер ияләренә сабак һәм ачык дәлилләр бар. Кем орлык бөртеген ярып төрле үсемлекләр үстерә? Кем җирдә елгалар агызды һәм җир астыннан чишмәләр чыгарды? Кем һәрнәрсәгә тиешле кыяфәтен бирде һәм үзләренең тормышларына кирәк булган файдалы әйберләргә юл күрсәтте? Кем кешеләрне төрле файдалы фәнни гыйлемнәргә өйрәтте? Кем тәмсез, коры сабаклардан матур кыяфәтле тәмле җиләк-җимешләр чыгарды? Кем барча тирәлекне хикмәтләр салып, төзек итеп, камил рәвештә урнаштырды? Кем туры юл күрсәтүче, кешеләрнең һәм җәмгыятьнең тормышын төзәтүче гаять камил булган шәригать кануннарын җибәрде? Кем тонналаган суны сыйдырган болытларны күтәреп йөртә, аннан бу суны җир өстендә булган әйберләргә зыян килмәсен дип вак тамчыларга бүлеп төшерә? Болар ачык билгеләр түгелме? Әллә шуларны эшләүче Зат, җан ияләрен үлемнән соң тергезергә сәләтле булмасмы?

Ул, Аллаһ Тәгалә – гыйбадәт кылырга лаеклы бердәнбер Зат, Аның патшалыгы беркайчан да юкка чыкмас, барча тирәлекне Үзенең рәхмәте белән чолгап алган һәм ризыкландырып тора, хәтта кечкенә генә бөртекләрне дә онытмаган. Авыртучыларның тавышларын ишетә, дога кылучыларга җавап бирә, тәүбәгә килүчеләрне гафу итә һәм рәхмәтен төшерә.

Һәм ахырдан, Аллаһтан Аның күркәм исемнәре һәм бөек сыйфатлары аша сорыйбыз – безгә камил иман, ныклы һәм дөрес инану бирсә иде, Аның ишетелә яки күренә торган, үзебездә һәм барча тирәлектә урнаштырылган аятьләрен тануны, фикерләүне һәм шуннан файда алуны җиңеләйтсә иде!

Мөхәммәд пәйгамбәргә, аның гаилә әһелләренә һәм сәхабәләренә, Кыямәт көненә хәтле булган иярүчеләренә Аллаһның мактавы, сәламе һәм бәрәкәте булсын! Үзебез, әти-әниләребез, исән яки вафат булган барча мөэмин-мөселманнар өчен Аллаһтан гафу сорыйбыз! Әмин!